**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТАКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17,с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

22.02.2019

КАРАР

______

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Зөбәер төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставын раслау турында

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Зөбәер төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставын (алга таба Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Зөбәер төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ яңа редакциядә расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Зөбәер төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе директорына, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Зөбәер төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе Уставын теркәгәндә мөрәҗәгать итүче булып чыгыш ясарга, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 18 нче номерлы районара салым инспекциясендә яңа редакциядә һәм башка үзгәрешләр кертергә, гаризаны, башка документларны имзаларга, кирәкле гамәлләрне һәм формальлекләрне башкарырга вәкаләт бирергә.

3. Әлеге карар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми басылып чыккан көненнән түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Җитәкче И.Ш.Бариев